РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Село Янурусово, улица Ленина, дом
43а, 423370 Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
Ленин урамы,43 а йорт, Янурыс
авылы, 423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

# КАРАР

**от 21.03.2024г.** **№3**

"Янурыс авыл җирлеге Янурыс торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс торак пунктында гражданар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге башлыгы

**Карар итә:**

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Янурыс авылы, Ленин урамы, 43 в йорт адресы буенча урнашкан Янурыс авылы клубы бинасында «Янурыс авыл җирлеге Янурыс торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Янурыс авыл җирлеге Янурыс торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 31 нче марты 13.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
"Янурыс авыл җирлеге Янурыс торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына түбәндәгечә редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

1. Янурыс ,Иске Әхмәт торак пунктында электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрен (урам яктырткычлары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру), трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны,бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау;

2. Янурыс ,Иске Әхмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү,ремонтлау,карап тоту(юлларны кардан чистарту(шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);Ленин ,8 Март урамнарында урнашкан зиратка баручы юлларга таш җәю ( махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү,таш ташу,урнаштыру,тигезләү)

3.Янурыс торак пункты территориясен төзекләндерү максатыннан чишмә ясау(махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү,таш ташу,урнаштыру,тигезләү,төзелеш материаллары сатып алу);хуҗасыз территорияләрне чабу өчен триммерлар сатып алу;җәйге вакытта юл кырларын чабу (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү),бензокосилкалар өчен,МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык сатып алу.

4.Янурыс торак пунктынлд традицион җирле урыннарны төзекләндерү максатыннан зиратларда биек агачларны,куакларны кисү(шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү,махсус техника арендалау).

«эйе» «юк».

4. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга .http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы А. Ә. Мөхәммәдиева